ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең җир кишәрлекләрен хосусыйлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәреш кертү хакында» 19-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты М.И. Галиев тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең җир кишәрлекләрен хосусыйлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәреш кертү хакында» 19-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ / АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2024 елның 23 декабре
№ 151-VII ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутаты
М.И. Галиев тарафыннан
кертелә

**«Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең җир кишәрлекләрен хосусыйлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәреш кертү хакында**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең җир кишәрлекләрен хосусыйлаштыру турында» 2003 елның 6 августындагы 28-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 8; 2005, № 12 (IV өлеш), аңа «муниципаль район» сүзләреннән соң «яисә шәһәр округы» сүзләрен өстәп, үзгәреш кертергә.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең җир кишәрлекләрен хосусыйлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына аңлатма**

«Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең җир кишәрлекләрен хосусыйлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты (алга таба – закон проекты) Татарстан Республикасы законнарын федераль законнарга туры китерү максатыннан эшләнде.

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 13 июнендәге 228-ФЗ номерлы Федераль законның 4 статьясы белән «Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр әйләнеше турында» 2002 елның 24 июлендәге 101-ФЗ номерлы Федераль законга түбәндәге үзгәрешләр кертелде:

1) 1 статьяның 3 пунктындагы 2 пунктчасына «муниципаль район» сүзләреннән соң «, муниципаль округ яисә шәһәр округы» сүзләре өстәлде;

2) 4 статьяның 2 пунктына «муниципаль район» сүзләреннән соң «, муниципаль округ яисә шәһәр округы» сүзләре өстәлде.

Шулай итеп, закон проекты белән «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең җир кишәрлекләрен хосусыйлаштыру турында» 2003 елның 6 августындагы 28-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына, аңа «муниципаль район» сүзләреннән соң «, муниципаль округ яисә шәһәр округы» сүзләрен өстәп, үзгәреш кертергә тәкъдим ителә.

Закон проектын кабул итү һәм аны алга таба гамәлгә ашыру законнарны федераль законнар нормалары нигезендә бертөрлелеккә китерергә, камилләштерергә һәм «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең җир кишәрлекләрен хосусыйлаштыру турында» 2003 елның 6 августындагы 28-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының аерым нигезләмәләрен актуальләштерергә ярдәм итәчәк.

**«Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең җир кишәрлекләрен хосусыйлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең җир кишәрлекләрен хосусыйлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яки кабул итүне таләп итми.

**«Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең җир кишәрлекләрен хосусыйлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын**

**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең җир кишәрлекләрен хосусыйлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә акчалар бүлеп бирүне таләп итми.